Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында бәйрәм көннәре һәм истәлекле көннәр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр керту хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2003 елның 3 сентябрендә кабул ителде

1 статья. «Татарстан Республикасында бәйрәм көннәре һәм истәлекле көннәр турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 4, № 9-10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 9), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында

1 статья. Татарстан Республикасында түбәндәге эш көне булмаган бәйрәм көннәре билгеләнә:

Татарстан Республикасы төзелү көне — 30 август;

Татарстан Республикасы Конституциясе көне — 6 ноябрь;

Корбан бәйрәме.

Татарстан Республикасында түбәндәге бәйрәм көне билгеләнә:

Туган тел көне – 26 апрель.

Корбан бәйрәмен үткәрү датасы ел саен аңа кадәр өч айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Президенты Указы белән игълан ителә.

Әлеге статьяда күрсәтелгән бәйрәм көннәре ял көненә туры килгән очракта ял көне бәйрәмнән соңгы эш көненә күчерелә.

2 статья. Татарстан Республикасында язгы кыр эшләре тәмамлану унаеннан татар халкы бәйрәме «Сабантуй» һәм рус халкы бәйрәме «Каравон» уздырыла. Әлеге бәйрәмнәрне үткәрү вакыты ел саен Татарстан Республикасы Президенты Указы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасында үзләрен аерым этник бергәлекләргә кертеп санаган гражданнар башка милли бәйрәмнәрне дә билгеләп үтәргә хокуклы. Этник төркемнәрнең тупланып урнашкан урыннарындагы җирле үзидарә территориясендә аларны үткәрү вакыты җирле үзидарә башлыгы, ә бер[illegible]ә җирле үзидарә территориясендә -- район яисә республика әһәмиятендәге шәһәр администрациясе башлыгы тарафыннан билгеләнә. Мондый бәйрәмнәрне бер районнан күбрәк территориядә, шулай ук республика әһәмиятендәге шәһәр территориясендә уздырган очракта, карар Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кабул ителә.

3 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан башка бәйрәм көннәре, шулай ук истәлекле көннәр билгеләнергә мөмкин.

Татарстан Республикасының профессиональ бәйрәм көннәрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тәкъдимнәре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгели.

4 статья. Бәйрәм көннәре һәм истәлекле көннәр унаеннан, дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм хезмәт коллективлары инициативасы белән иҗтимагый-сәяси характердагы чаралар уздырыла.

5 статья. Татарстан Республикасында гражданнар дини бәйрәмнәрне билгеләп үтәргә хокуклы.

Конфессияләр вәкилләренә, аларның үтенече буенча, дини бәйрәмнәрне көненда чираттагы еллык яллары исәбеннән йә хезмәткәр белән килешенгән башка шартларда, милек рәвешләренә һәм эшчәнлек өлкәләрснә бәйсез рәвештә, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар администрацияләре тарафыннан өстәмә ял көне бирелә.».

2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

М.Ш.Шәймиев

Казан, Кремль
2003 елның 23 сентябре
№ 39-ЗРТ

4/bairam